**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2020елның 26 августы 1718 номер

# КАРАР

**Столбище авыл җирлеге, Усад авылы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, план структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләре урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында карар бирәм:

1. Лаеш муниципаль районында, Столбище авыл җирлегендә, Усад авылында, торак һәм коммерциячел объектлар төзү планлаштырыла торган җир кишәрлекләрендә территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләргә:

- күпкатлы торак төзелеше түбәндәге кадастр номерлары белән: 16:24:150304:78, 16:24:150304:499, 16:24:150304:746, 16:24:150304:747, 16:24:150304:224, 16:24:150304:680, 16:24:150304:6037, 16:24:150304:6036, 16:24:150304:2797, 16:24:150304:2793, 16:24:150304:5645;

- булган эшлекле, иҗтимагый һәм коммерциячел билгеләнештәге зона 16:24:150305:4872 кадастр номеры белән.

1. 2020 ел дәвамында Лаеш муниципаль районында, Столбище авыл җирлегендә күрсәтелгән территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын эшләү срогын билгеләргә.

2. Территорияне планлаштыру һәм ызанлау документларын әзерләү һәм тоту тәртибе турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан эш көннәрендә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Лаеш шәһәре, Чернышевский ур., 23 й..

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм «Кама ягы» («Камская новь») район газетасында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.П. Шитов**